Утверждено на Совете школьников
протокол № 1 от 04.09.17г.

Согласовано :
Директор школы МБОУ
«Большетиганская ООШ»
_______________/И.Н.Галимов/

# Устав детской организации

# «Республика цветов»

# МБОУ «Большетиганская ООШ»

# Алексеевского муниципального района РТ

1.“Чәчәкләр Республикасы” исемендәге балалар оешмасының уставы Татарстан Варислар берлегенең уставына нигезләнеп төзелде.
2. “Чәчәкләр Республикасы” оешмасының **максаты:**
“ Күңелле һәм мәгнәле тормыш белән яшәү!”.
**Бурычлар:**
а) интеллектуаль, эшлекле, иҗади шәхес буларак үсәргә ярдәм итү;
б) татар халкында элек – электән сабырлык, күңел байлыгы, киң күңеллек кыйммәтле саналган. Менә шул сыйфатлар үзеңдә үстерергә ярдәм итү.
3. **Девиз:** “Без бергә үсәрбез, чәчәк атарбыз һәм бер бәйләм чәчәк булып яшәрбез !”

4.**Гимн:** “Гөлбакча иле”

Атадык мәктәбебезн , “ Гөлбакча иле”.

Һәрвакыт шат авазлардан, Тынмасын иде.

Бәхет һәм шатлыклар белән, Яшибез бергә.

Хәсрәт һәм кайгылар гына, Килмәсен безгә.

Кушымта:

“Гөлбакча иле”(2)

Кулга –кул тотонышып, Берләшсәк иде.

Яратабыз мәктәбебезне, һәр кайсыбыз да

Үткәрәбез һәр көн диярлек, Бәйрәмнәр монда

Дуслар белән гел янәшә, Шау гөр киләбез.

“Чәчәк ат озак яшә”,- дип Сиңа дәшәбез.

(җырның авторы 8-11 кл укучылары. “Маленькая  страна көе”.)

4. **Символика:** “Чәчәкләр Республикасы” ның эмблемасы төрле чәчәктән тора.
   Флагы: Татарстан флагына “Чәчәкләр республикасы” ның эмблемасы төшерелгән.
   Талисманы: Кояш
5. **Төзелеше:** “Чәчәкләр республикасы”исемендәге балалар оешмасына 1-11 нче сыйныф укучылары ирекле рәвештә керә һәм чыга ала. Һәр сыйныф “Чәчәкләр республика”сының шәһәре ролен үти .Алар чәчәк исеме белән атала.
6. **Югары органы:** “Чәчәкләр республикасы” ның җыены.
7. **Эшләүче органы**: Югары советы.

***“ЧӘЧӘКЛӘР РЕСПУБЛИКАСЫ”НЫҢ ЮГАРЫ ОРГАНЫ.***

“Чәчәкләр республикасы” ның югары органы җыены. Ул елына 2 тапкыр уздырыла.

1-се “Көзге каенлыкта” дип атала. Бу җыен ТВБ (СНТ) нең туган көне хөрмәтенә, Чәчәкләр республикасына варислар кабул итү уңаеннан урманда уздырыла.

2-се “Без учак янында” дип атала. Бу җыен Пионер көненә багышлана. Ел буена эшләнгән эшләргә анализ ясала, төрле уеннар, ярышлар уткәрелә.

**“Чәчәкләр респубикасы” ның эшләүче органы**

**ЮГАРЫ СОВЕТЫ**

Югары советы – президент җитәкчелегендә министрлар.Югары советында эшләүче укучылар, мәктәп укучыларының әйдаманнары (лидерлары)

**ЮГАРЫ СОВЕТЫНЫҢ ХОКУКЛАРЫ**

1. Югары советы эшләргә өч кеше теләк белдерсә, аның балалар оешмасы буларак яшәргә хокуклары бар.
2. Югары советы “Чәчәкләр республикасы” оешмасының программасы, уставы төзергә хокуклы. Оешманың эш планын, бурыч һәм максатларын, атрибутикасын билгели ала. Үз контроль, эшкә анализ ясый.

**ПРЕЗИДЕНТНЫҢ БУРЫЧЫ ҺӘМ ХОКУКЛАРЫ**

1. Президент – мәктәпнең актив җитәкчесе (лидеры, әйдаманы).
2. Өлкән әйдаман белән берлектә Президент советы эшен башкара.
3. Үзенә соңгы президентка кандидат сайлап куя ала. Сайланмаган очракта, сайлаулар уздырыла.

**МИНИСТРЛАРНЫҢ ХОКУК ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ**

1. Һәр министр (командир, әйдаман) президент советының әгъзасы булып тора.
2. Президент советы утырышында үзенең фикерен, тәгъдимен кертә ала.